**Татарстан Республикасы Хөкүмәте (Россия Федерациясе)
һәм Нәваи өлкәсе Хакимияте (Үзбәкстан Республикасы)
арасында сәүдә-икътисадый, фәнни-техник, социаль
һәм мәдәни-гуманитар өлкәләрдә хезмәттәшлек турында
КИЛЕШҮ**

Татарстан Республикасы Хөкүмәте (Россия Федерациясе) һәм Нәваи өлкәсе Хакимияте (Үзбәкстан Республикасы), алга таба «Яклар» дип аталып,

Россия Федерациясе һәм Үзбәкстан Республикасы арасында 1992 елның 30 маендагы дәүләтара мөнәсәбәтләр, дуслык һәм хезмәттәшлек нигезләре турында Шартнамә, Россия Федерациясе һәм Үзбәкстан Республикасы арасында 1992 елның 13 ноябрендәге сәүдә элемтәләре турында Килешү, Россия Федерациясе һәм Үзбәкстан Республикасы арасында 2005 елның 14 ноябрендәге союздаш мөнәсәбәтләр турында Шартнамә, Татарстан Республикасы Хөкүмәте һәм Үзбәкстан Республикасы Хөкүмәте арасында 1993 елның 18 февралендәге сәүдә-икътисадый, фәнни-техник һәм мәдәни хезмәттәшлек турында Килешү, Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм Үзбәкстан Республикасы Хөкүмәте арасында 2017 елның 5 апрелендәге төбәкара хезмәттәшлеккә ярдәм итү турында Килешү нигезләмәләренә таянып,

Якларның тотрыклы һәм дәвамлы нигездә хезмәттәшлекне үстерүдә һәм киңәйтүдә үзара кызыксынганлыгын игътибарга алып,

Якларның һәр икесе мәнфәгатьләрендә сәүдә-икътисадый, фәнни-техник, социаль һәм мәдәни-гуманитар өлкәләрдә элемтәләрне үстерү мөмкинлекләрен үзара файда нигезендә нәтиҗәлерәк файдаланырга омтылып,

түбәндәгеләр турында сүз куештылар:

**1 статья**

Әлеге килешүнең максаты – Россия Федерациясе законнары һәм Үзбәкстан Республикасы законнары, шулай ук Россия Федерациясе һәм Үзбәкстан Республикасы катнашындагы халыкара шартнамәләр нигезендә Яклар арасында сәүдә-икътисадый, фәнни-техник, социаль, мәдәни-гуманитар өлкәләрдә хезмәттәшлекне киңәйтү һәм ныгыту.

Яклар әлеге Килешү кысаларында, аны намуслы һәм нәтиҗәле үтәү максатларында үз эшчәнлекләрен тиешле рәвештә координацияләү өчен тырышлык куя.

## 2 статья

Яклар үз компетенцияләре чикләрендә сәүдә-икътисадый, фәнни-техник, социаль, мәдәни-гуманитар өлкәләрдә хезмәттәшлекне үстерүнең торышын һәм мөмкинлекләрен игътибарга алып, түбәндәге юнәлешләрдә хезмәттәшлек итә:

а) Татарстан Республикасы (Россия Федерациясе) һәм Нәваи өлкәсе (Үзбәкстан Республикасы) территорияләрендә теркәлгән хуҗалык субъектлары (алга таба – хуҗалык субъектлары) арасында үзара файдалы хезмәттәшлеккә булышлык күрсәтү;

б) җитештерү, инвестицияләр кертү һәм коммерция өлкәләрендә уртак эшчәнлекнең нәтиҗәле формаларын үстерүгә, шулай ук хуҗалык субъектларының күпьяклы элемтәләре өчен уңай шартлар булдыруга ярдәм күрсәтү;

в) химия сәнәгате, машиналар төзү, авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек җитештерү өлкәсендә хуҗалык субъектларының эшкуарлык яисә башка төрле эшчәнлеге, шулай ук транспорт инфраструктурасы, торак, сәнәгать һәм техник объектлар төзү хезмәтләре күрсәтү өчен уңайлы эшлекле даирә булдыруга ярдәм күрсәтү;

г) фәнни оешмалар арасында һәм фәнни-техник хезмәттәшлек мәсьәләләрен үзара файда нигезендә хәл итүдә турыдан-туры элемтәләрне үстерү;

д) Татарстан Республикасы (Россия Федерациясе) һәм Нәваи өлкәсе (Үзбәкстан Республикасы) территорияләрендә яши торган халыкларның тарихына, рухи хәзинәләренә, йолаларына һәм традицияләренә хөрмәтле мөнәсәбәтне тәэмин итеп, аларның мәдәни яктан якынаюына һәм бер-берсен баетуына ярдәм күрсәтү;

е) Татарстан Республикасының (Россия Федерациясе) һәм Нәваи өлкәсенең (Үзбәкстан Республикасы) яшьләр оешмалары һәм яшьләр сәясәте мәсьәләләре белән шөгыльләнүче учреждениеләре арасында дустанә һәм партнерлык мөнәсәбәтләрен үстерүгә булышлык итү;

ж) үзара кызыксындыру тудырган башка юнәлешләрдә хезмәттәшлекне үстерү.

**3 статья**

Яклар Россия Федерациясе законнары һәм Үзбәкстан Республикасы законнары нигезендә әлеге Килешүне тормышка ашыруга юнәлдерелгән программалар һәм (яисә) чаралар планнары эшләргә һәм кабул итәргә, шулай ук әлеге Килешүне тормышка ашыруга юнәлдерелгән программалар һәм (яисә) планнарның үтәлешенә булышлык итү һәм тиешле күзәтчелек эшен башкару максатларында Татарстан Республикасы Хөкүмәте (Россия Федерациясе) һәм Нәваи өлкәсе Хакимияте (Үзбәкстан Республикасы) эшчәнлеген координацияләү өчен уртак комиссияләр һәм (яисә) эш төркемнәре төзергә мөмкин.

Әлеге Килешү нигезендә тәгаен проектлар, программалар, планнар һәм башка килешүләр Россия Федерациясе законнары һәм Үзбәкстан Республикасы законнары нигезендә турыдан-туры Яклар тарафыннан тормышка ашырыла.

Яклар, Россия Федерациясе законнары һәм Үзбәкстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнгән очраклардан тыш, әлеге Килешүне тормышка ашыру кысаларында хуҗалык субъектлары арасында төзелгән шартнамәләр һәм контрактларга нигезләнгән йөкләмәләр буенча җаваплы булмый.

**4 статья**

Яклар Россия Федерациясе законнары һәм Үзбәкстан Республикасы законнары нигезендә үз компетенцияләре чикләрендә:

а) уртак предприятиеләрнең эшләве, үзара кызыксындыру тудырган уртак проектларны һәм программаларны эшләү һәм тормышка ашыру өчен тиешле оештыру, финанс-икътисадый һәм хокукый шартлар булдыра;

б) хуҗалык субъектларының Яклар тарафыннан уздырыла торган ярминкәләрдә, күргәзмәләрдә һәм башка чараларда катнашуына ярдәм итә, сәүдә-икътисадый, фәнни-техник, социаль, мәдәни-гуманитар өлкәләрдә төрле юнәлешләр буенча мәгълүмат алмаша;

в) төрле өлкәләрдә делегацияләр һәм белгечләр алмашуга ярдәм итә, шулай ук хуҗалык субъектлары арасында сәүдә-икътисадый, фәнни-техник, социаль, мәдәни-гуманитар өлкәләрдә хезмәттәшлек алып бару мөмкинлеген күздә тота.

**5 статья**

Әлеге Килешү нигезендә Яклар тарафыннан алынган мәгълүмат өченче якларга бары тик Россия Федерациясе законнары һәм Үзбәкстан Республикасы законнары нигезендә һәм әлеге мәгълүмат алынган Яктан язмача рөхсәт булганда гына бирелә ала.

Шул ук вакытта әлеге Килешү кысаларында Яклар Россия Федерациясе законнары һәм Үзбәкстан Республикасы законнары нигезендә дәүләт, коммерция сере яисә закон нигезендә саклана торган сер булып торган башка мәгълүмат алмашмый.

**6 статья**

Яклар Россия Федерациясе законнарындагы һәм Үзбәкстан Республикасы законнарындагы әлеге Килешү нигезләмәләрен планлаштырылган чаралар кысаларында үтәүгә йогынты ясавы мөмкин булган барлык үзгәрешләр турында бер-берсенә хәбәр итә.

**7 статья**

Әлеге Килешү Якларның өченче яклар белән төзелгән шартнамәләре нигезендә барлыкка килгән хокукларына һәм йөкләмәләренә кагылмый.

Әлеге Килешү аңа кул куйган Якларга финанс һәм (яисә) мөлкәт йөкләмәләре салмый.

**8 статья**

Әлеге Килешүнең нигезләмәләрен шәрехләү һәм куллану белән бәйле бәхәсләр һәм башка мәсьәләләр Яклар арасында сөйләшүләр һәм консультацияләр уздыру юлы белән хәл ителә.

**9 статья**

Якларның ризалыгы белән әлеге Килешүгә аерым беркетмәләр белән рәсмиләштерелә торган үзгәрешләр кертелергә мөмкин.

**10 статья**

Әлеге Килешү Яклар тарафыннан аның үз көченә керүе өчен кирәкле барлык эчке процедураларның үтәлүе турында соңгы язма хәбәрнамә алынган көннән үз көченә керә.

Әлеге Килешү билгесез срокка төзелә һәм Якларның берсенә икенче Якның әлеге Килешүнең гамәлен туктату нияте турында язмача хәбәре килгән көннән бер ай узганнан соң аның гамәле туктала.

Әлеге Килешүнең гамәлен туктату әлеге Килешү нигезендә тормышка ашырыла торган контрактларны, шартнамәләрне, беркетмәләр һәм программаларны үтәү буенча йөкләмәләргә кагылмый.

Ташкент шәһәрендә 2025 елның «28» апрелендә һәркайсы рус, татар һәм үзбәк телләрендә ике нөсхәдә башкарылды, барлык текстлар бер үк көчкә ия.

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Хөкүмәте (Россия Федерациясе) өчен | Нәваи өлкәсе Хакимияте (Үзбәкстан Республикасы) өчен |
| _______________ Р.Н. Миңнеханов | _______________ Н.Т. Турсунов |

03.06.2025
№ 15